РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ | КАРАР

№ 13 | 2026 елның 27 феврале

**«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Советы 2023 елның 06 апрелендәге 24 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында» Түбән Кама муниципаль районы Советының 2025 елның 13 октябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль законның 59 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 73 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Түбән Кама муниципаль районы Советы 2023 елның 06 апрелендәге 24 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында» Түбән Кама муниципаль районы Советының 2025 елның 13 октябрендәге 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Үз көчен югалткан дип танырга:

«Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 71 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Советы карары;

«Түбән Кама муниципаль районы Советының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 71нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 декабрендәге 83 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Советы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы

Р.И. Беляев